ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘГЕРҖЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫң
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Гагарин ур.,13, Әгерҗе шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-22-46; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«27» апреля 2026 ел № 103

«Әгерҗе муниципаль районы территориясендә сугыш вакытында һәм гадәттән тыш хәлләрдә оешмалар (предприятиеләр, учреждениеләр) эшчәнлегенең тотрыклылыгы турында нигезләмәне раслау һәм Әгерҗе муниципаль районы территориясендә хәрби вакытта һәм гадәттән тыш хәлләрдә оешмалар (предприятиеләр, учреждениеләр) эшчәнлегенең тотрыклылыгын арттыру комиссиясе составын раслау турында» Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 05 мартындагы 82 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 31 декабрендәге 109-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына таянып, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. «Әгерҗе муниципаль районы территориясендә сугыш вакытында һәм гадәттән тыш хәлләрдә оешмалар (предприятиеләр, учреждениеләр) эшчәнлегенең тотрыклылыгы турында нигезләмәне раслау һәм Әгерҗе муниципаль районы территориясендә хәрби вакытта һәм гадәттән тыш хәлләрдә оешмалар (предприятиеләр, учреждениеләр) эшчәнлегенең тотрыклылыгын арттыру комиссиясе составын раслау турында» Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 05 мартындагы 82 номерлы карарына түбәндәге узгәрешләрне кертергә:

- 1 бүлекнең 1.4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Үз эшчәнлегендә Комиссия Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль конституциячел законнарга, федераль законнарга, Россия Федерациясе Президенты Указларына һәм күрсәтмәләренә, Россия Федерациясе Хөкүмәте карарларына һәм күрсәтмәләренә, Татарстан Республикасы Конституциясенә, Татарстан Республикасы законнарына, Татарстан Республикасы Башлыгы (рәисе) указларына һәм күрсәтмәләренә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарларына һәм күрсәтмәләренә, районның муниципаль норматив-хокукый актларына, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таяна».

2. Әлеге карарны "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (http://agryz.tatarstan.ru).

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

**Җитәкчесе** **И.Х. Салихов**